# «ТӘГӘРӘСЕН ЙОМГАГЫМ»
## Мәхмүт Газизовка
## 75 ел тулу уңае белән әдәби-музыкаль кичә
*(4-5 нче сыйныф укучылары өчен)*

*Талгын гына көй агыла, сәхнәгә ике алып баручы чыга.*

**1 нче алып баручы:**

...Тәгәри китте йомгагым,
Йомгак түгел – җырларым,
Йомгак очын мин, дусларым,
Сезгә бирәм, сезнең кулга
Тәгәрәсен йомгагым.

«*Йомгак очы*»

**2 нче алып баручы:** Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар, кунаклар. Кичәбезне, Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат иткән, шагыйребез Мәхмүт Газизов шигыреннән өзек укып, башлап җибәрдек. Әгәр дә, Мәхмүт Газизов исән булса аңа 75 яшь булыр иде. Яшәрлек, яшьнәрлек яшьтә бит. Ләкин шагыйребез безнең янәшәдә юк инде.

**1 нче алып баручы:** Кадерле укучылар, бүген без сезнең белән бергә Мәхмүт Газизовның шигъри йомгакларын сүтеп карыйк әле.

Әдипнең иҗат эшчәнлеге урта мәктәптә укыганда башлана. Аның «Такташ безнең белән» исемле беренче шигыре тугызынчы сыйныфта укыган вакытта, Шөгер (хәзерге Лениногорск) районында чыгып килүче «Җиңү байрагы» газетасында басыла.

**2 нче алып баручы:**

Такташ үлгән диләр...
Безнең өчен
Ошамый бу дөрес хәбәргә.
Мин килешмәс идем,
Берәр кеше:
Онтылыр ул, дисә әгәр дә.
Ул үлмәгән!
Аның исеме исән,
Киләчәккә өндәп эндәшә.
Ул үлмәгән!
Безнең белән бергә
Җирдә хаклык өчен көрәшә.

**1нче алып баручы:** Кайсы шагыйрь үзе дөньяга аваз салган, беренче адымнарын атлаган урынына мәдхия җырламаган! Мәхмүт Газизовның да туган ягына багышлап язган шигырьләре шактый.

*Укучылар чыгышы.*

**1 нче укучы:**

Туктар, белмим, исем булгандырмы,
кушаматмы әллә нибары,
кенәгәдә писарь язып куйган
сүзләр калган: «Туктар-Урдалы».
Нишләп туктасын дип безнең авыл,
озын сүзне артык эш күргән,
күбесенчә Урдалы ди халык,
«Туктар» дигән җирен төшереп.
Барган авыл, әйе, туктамаган,
туктар чиккә ничә җитеп тә,
алга барган,
барган җәяүләп тә,
ат булмаса үгез җигеп тә...

**2 нче укучы:**

Тәгәрмәчкә тарих сукмагында
күпме тирес, пычрак уралды,
таяк тыкты кемнәр, аяк тыкты,
камыт бавын кисте-турады,
дилбегәне тоткан ир-улларны
урып алды сугыш урагы, -
туктамады барыбер, олы юлны
эзләп чыккан Туктар-Урдалы.
Олы юл кадерен Урдалыга
әйтәсе юк – элек-электән
ул үзе дә зур юллардан читтә,
бер кырыйда яшәп интеккән...

**3 нче укучы:**

Кешеләргә ана сөте белән
җир җылысы керсә җилеккә,
көл өстендә ил тамыры корымый,
яши икән авыл ничек тә!

Үтелгән юл шаһит: «Туктар» дигән
мөһер суккан писарь уңмады,
«Каршы тау»лар ярып юлга чыккач,
туктамастыр Туктар-Урдалы.!

«*Туктар-Урдалы*»

**2нче алып баручы:** Мәхмүт Миннәхмәт улы Газизов 1940 елның 8нче февралендә Лениногорск районының Туктар-Урдалысы авылында туа. Авыл мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Институтта укыган чорда әдип сабакташларына багышлап та шигырьләр иҗат итә.

**1 нче алып баручы:**

Без яшәдек бергә
егерме йөрәк,
егерме студент,
егерме мәхәббәт.
Дуслык җебе белән уралдык без –
Егерме кеше,
Егерме куәт.
Шул егерме йөрәк хәзер
егерме җирдә,
егерме сагыну
егермебездә.

«*Егерме йөрәк*»

**2 нче алып баручы:** Институтта ул хәзерге көндә шагыйрь Ренат Харис, егерме елдан артык «Мәгариф»журналы мөхәррире булып эшләгән Фәрит Шәрифуллин, күп еллар Татарстан телевидениесендә диктор булган Рөстәм Нәбиуллин белән бергә укый, ә старосталары бүгенге көндә тарих фәннәре докторы, археолог-галим Равил Фәхретдинов була.

**1 нче алып баручы:** Мәхмүт Газизов уку чорында иҗатчылар түгәрәгенә йөреп, шагыйрьләребез Илдар Юзеев, Барлас Камалов, Хисам Камалов, Марс Шабаевлар белән аралаша. Бу очрашулар да аның шагыйрь булып китүенә этәргеч булмый калмагандыр.

**2 нче алып баручы:** Югары белемле Мәхмүт Газизовның хезмәт юлы Лениногорск районы Федотовка авылы урта мәктәбендә башланып китә. Ул татар әдәбияты, тарих-җәмгыять белеме дәресләреннән балаларга белем бирә. Шуңа күрә, аңа балалар тормышы якын иде, ул, балалар телен аңлап, балалар тормышын чагылдырган шигырьләрен яратып язды. Ул балалар дөньясына сабыйларча гашыйк шагыйрь иде.

*Укучылар чыгышы.*

**4 нче укучы:**

Җимеш кирәк бәлешкә,
барыйк икән кай төшкә?

–Җимеш-җимеш, син кайда?

– Баланда мин, баланда.
– Балан-балан, син кайда?
– Болында мин, болында.
– Болын-болын, син кайда?
– Түгәрәк күл буенда.
– Тәгәрәк күл, син кайда?
– Тугайга кил, мин монда!

Тугайда күлне күреп,
Болын эченә кереп,
Баланның иң кызылын
Җыеп йөрдек көн озын.
Балан-балан бал гына,
Тәмле икән җимеше.
Әнигә – туган көнгә! –
Бүләк булды бәлеше.

*«Балан»*

**5 нче укучы:**

Шахмат булып уйнадык –
шах, мат куеп уйнадык.

«Король» Кәрим мактана,
мин хуҗа, ди, тактада.
зинһар, дибез, мактанма,
күп сөйләшеп мат алма.

Әй сикерә, чаба ат,
ат дигәнем – Салават.
Кәримне чак отмады,
ярый куып тотмады.

Чаптык алга табан да,
артка, янга табан да,
шах биреп мат куймыйча
туктамадык һаман да.

Барыбер җиңдек «Король»не –
ул мактанчык Кәримне.

«*Мактанчык Кәрим*»

***6 нчы укучы:***

– И син көчек-көчеккәй,
Иренмисең ничек, әй!
Йөгерәсең-чабасың,
Качсам эзләп табасың.

Эт койрыгын уйнатты –
Эндәшкәнне яратты.

– Һау, коймагың и-кәү, – ди, –
Берсен бирсәң и-икән, – ди.
– Бирәм-бирәм, җәлләмим,
Саранмы соң әллә мин?!
Мә, күчтәнәч булсын ул,
Дуслыгыбыз өчен ул.

Эт койрыгын уйнатты –
Күчтәнәчне яратты.

«*Күчтәнәч*»

**1 нче алып баручы:** Мәхмүт Газизов 1970 елда Чаллыга КамАЗ төзелешенә килә. Анда тулай торакта тәрбияче, төзелештә геодезист, мастер, тимерчелек заводында эшче булып эшли. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсен җитәкли. Әдип әнә шулай тормышны өйрәнә, булачак әсәрләре өчен материал туплый.

**2 нче алып баручы:** Шәһәрдәге зур үзгәрешләр, яңарыш шагыйрьгә шигырьләрендә яңа образлар тудырырга ярдәм итә. Мәхмүт абыйның хезмәт кешесе турындагы шигырьләре табигый, уй-хисле, тормышчан. Аның өчен гомумилек ят нәрсә. Шигырьләрдә конкрет фикер, хис ята.

**1 нче алып баручы:**

Ватан
сукты чаңны:
– Чаллы!
– Чаллы!!
– Чаллы!!!
Ә яшьлекне зәңгәр
юллар дәшкән чагы,
күңел җилкенергә
нәрсә кирәк тагы?!

«*Өмә*»

**2нче алып баручы:**

Бәйрәм бүген –
Көмеш салдык без,
Нигезләр, дип, булсын мөбарәк.
Шул йоланың серле көченә
Ышанасы килә мең кабат.

«*Безнең урамга да бәйрәм килде*»

**1 нче алып баручы:**

Эш белән мавыгып, төн үткән,

яктырып килә ич, кара син! –
без салган нигезләр өстендә
өлгерә тагын бер
яңа көн!

*«Авырлык үзәге»*

**2 нче алып баручы:** Шагыйрь буларак ул эзләнә, КамАЗ белән бергә үсә. Мәхмүт Газизов 1978 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Шәһәребездә ул булмаган балалар бакчасы, мәктәп, китапханәләр юктыр. Әдип балалар белән очрашуларда, төрледән-төрле уеннар уйнатып, санамыш, тизәйткечләр әйттерә, балаларның уеннарда катнашуын ярата иде.

Мәхмүт Газизов 2013 елның 14нче сентябрендә каты авырудан соң вафат булды.

**1 нче алып баручы:** Сәхнәбез түренә янәдән укучыларны чакырам.

*4-5 укучы чыга, алып баручы аларга санамыш әйтә.*

**2 нче алып баручы:**

Арыш, бодай
Бүләбез,
Аны болай
Бүләбез:

– Җитез, уңган,
Таза, нык.
Таза, ныкка –
Биш капчык.
Ялкау, сытык,
Мактанчык.
Мактанчыкка –
Буш капчык.

Буш капчык, уеннан чык!

*«Буш капчык»*

*Санамышта уеннан беренче чыккан укучыга җаза бирелә.*
*Ул шагыйрьнең бер тизәйткечен әйтергә тиеш.*

**1 нче укучы:**

Өч ат, биш ат – сигез ат,
Сигез дә бер – тугыз ат.
Тугыз атта тугыз карт
Кыр әйләнде тугыз кат,
Кырдан уңыш алыр чак.

Тугыз атта тугыз карт,
Тугызы да тырыш карт:
Төяделәр тыгызлап, –
Алып кайттылар кабак,
Кырда – эре, өйдә – вак...

**1 нче алып баручы:** Татар шигъриятендә аның ачышлары, табышлары зурдан, ул үз сүзен әйтеп китте. Шагыйрь шигырьләре аша үз-үзенә мөрәҗәгать итәргә, үз күңелен күрергә дә онытмады.

Башың имә, билең бирмә,
я, сыкранма, бул адәм, –
Шөгер чагың үтсә-үткән,
шигырь чагың үтмәгән!

**2 нче алып баручы:** Мәхмүт Газизов: *«...Минем күп китапларым, нигездә, ата-аналарга, укытучыларга, тәрбиячеләргә адресланган. Алар – татар теленең кулланышын киңәйтү максатында менә дигән шигъри дәреслекләр»,* – дип сөйли иде.

**1 нче алып баручы:** Укучылар, игътибарлы булыгыз! Без сезнең белән тагын бер «Исемемне бел» дигән уен уйнап алабыз. Мин сезгә Мәхмүт Газизовның шигырьләрен укыйм, ә сез, җөмләнең беренче хәрефләрен җыеп, исемен атарга тиеш буласыз. Башладык, игътибар белән тыңлагыз.

**2 нче алып баручы:**
**Р** әмзия дә, Зилә дә,
**Ә** лфия дә, Дилә дә,
**З** әмзәмия дә түгел, -
**И** семем башка минем.
**Л** әкин монда бар ул сүз,
**Ә** йт әле, нинди исем?

*Укучы җавабы.*

**2 нче укучы: Р Ә З И Л Ә**

**1 нче алып баручы:** Бик дөрес җавап – **РӘЗИЛӘ.** Уенны дәвам итәбез.
**Р** әхмәт сиңа, үскәнем.
**Ә** киятләр дә беләсең,
**М** әкальләр дә беләсең, -
**З** ирәк бала икәнсең.
**И** ке икең – биш...дисәм дә,
**Л** әм-мим дәшми тормыйсың
**Ә** йтәсең дә бирәсең.

*Укучы җавабы.*

**3 нче укучы: Р Ә М З И Л Ә**

**2 нче алып баручы:** Бик дөрес җавап – **РӘМЗИЛӘ.** Уенны дәвам итәбез.

**Р** әхәтләнеп көлдем лә!
**Ә** крен генә килде дә:
**М** ин кем, бел, дип артымнан
**И** ке күзем каплады.
**Л** ото уйнарбыз бергә,
**Ә** гәр дөрес тапсаң, ди.

«*Исememне бел*»

*Укучы җавабы.*

**4 нче укучы: Р Ә М И Л Ә**

**1 нче алып баручы:** Бик дөрес җавап – **РӘМИЛӘ.** Уен тәмам.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Миңа уен-көлке дә, –
Мәшәкать кыз кешегә:
Яз килдеме, кызларның
Сипкел чыга битенә...

Чынлап менә икмәктер,
Быелгы яз нишләптер
Сипкеллерәк, гөллерәк,
Сөйкемлерәк, хикмәттер.

Сипкел-сипкел, сибелде,
Бөтен дөнья сипкелле:
Күк йөзендә йолдызлар
Сипкелләрең шикелле.

Сипкел-сипкел, сипкелләр
Бит очына сибелгән.
Шул сипкелләргә карап:
«Сөйкемле бит син», – диләр.

«*Сипкелле яз*»
*(Иңбер Шәфыйков көе, Мәхмүт Газизов сүз.)*

**2 нче алып баручы:** «Юл эше» дип исемләнгән шигырендә шагыйрь болай ди:

Юл тузаны куна чәчләргә,
ел тузаны кунар – юылмас:
юл киңәйткән искә төшәр дә
үткән гомер әрәм тоелмас.

**1 нче алып баручы:** Шагыйрь Мәхмүт Газизовның гомере әрәм үтмәде, ул безгә дистәгә якын шигъри җыентыкларын калдырып китте.«Бер, ике, өч...» (1972), «Миләш сиртмә» (1969), «Тәгәри китте йомгагым» (1976), «Мәйдан» (1990), «Гаҗәеп көн» (1995), «Серле иҗек» (1996) һәм «Бүремалай белән Аюбай» (2012).

**2 нче алып баручы:** Шагыйрь Мәхмүт Газизовның шигъри йомгагын сүтүне тәгәлләп кичәне шушы шигырь юллары белән тәмамлыйсы килә.

Күз яше төсле гөнаһсыз
Җыр язалсам әгәр.
Кулга каләм алган көнемә
Рәхмәт –
таулар кадәр

**1 нче алып баручы:** Шагыйрь абый, синең шигырьләр барлык татар балаларына килеп ирешкән, алар укучылар күңелендә мәңге яшәр.

**Файдаланылган әдәбият**

Газизов, М. Гаҗәеп көн: шигырьләр / М.Газизов. – Чаллы: «КамАЗ» нәшр., 1993. – 64 бит.

Мәхмүт Газизов: биобиблиографик күрсәткеч / Төз. Р. Хәмидуллина. – Яр Чаллы: 2000. – 43 бит.

Газизов, М. Сипкелле яз: [җыр] / М.Газизов сүз., Иңбер Шәфыйков көе. Нотасы белән / М. Газизов // Нур. – 2000. – 18 февраль. – Б.4.

Газизов, М. Бүремалай белән Аюбай: балалар өчен шигырьләр һәм экиятләр / М. Газизов: [рәссамы Заһир Хәкимов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 80 бит.